СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы**

**К А Р А Р Ы**

**« 22 » октябрь 2018 ел** **№ 13**

**« Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү күләме һәм шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 5 номерлы Ташкичү авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 17 мартындагы 940 номерлы карары нигезендә Ташкичү җирлеге советына түбәндәгеләр хәл итте:

1. Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советы карарына « 25 » апрель «Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәре һәм шартлары турында» 2018нче ел, №5

1) «Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге органнары хезмәткәрләренең һәм Ташкичү авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 5 номерлы карарының 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә һәм 01.04.2018 белән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.»;

2) Арча муниципаль районының 2018 елның 25 апрелендәге 2 нче номерлы Ташкичү авыл җирлеге Советы карарына 1нче кушымтаның 5 нче абзацы. «Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек башлыгын ай саен акчалата бүләкләү елына 6,72 айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмнәрдә билгеләнә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында Ташкичү авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин